ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.05.2026 г.Лениногорск № 349

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында яисә күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын һәм мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен сайлау турында карар кабул итмәгән урыннар милекчеләре өчен торак урын өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау хакында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгы белән, гамәлдәге законнар нормаларын үтәү максатларында «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәсе һәм дәүләт һәм муниципаль торак фондына наем шартнамәсе буенча торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен, шулай ук күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән яки күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен, 2026 елның икенче яртыеллыгына 148,88 процент күләмендә.

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3.Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 01 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче И.А. Шәмәрданов

Н. Сосунова
5-19-26